КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 734

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 5 сентябрь, 638 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 30 декабрь, 1020 нче, 2016 ел, 15 апрель, 228 нче, 2016 ел, 29 декабрь, 1029 нчы, 2017 ел, 25 март, 180 нче, 2017 ел, 27 ноябрь, 914 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1062 нче; 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының $69^2$ статьясындагы 3 пункты нигезендә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләрен (классификаторларын) һәм физик затларга күрсәтелә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләрнең һәм аларны башкару Россия Федерациясенең

норматив хокукый актларында каралган эшләрнең федераль исемлекләрен (классификаторларын) формалаштыру, алып бару һәм раслау турында» 2017 елның 30 августындагы 1043 номерлы карарын тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль учреждениеләр күрсәтә (башкара) һәм бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин